КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 июнь г.Казань № 502

Әлмәт муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖнең Әлмәт муниципаль районында урнашкан, 221,7606 гектар гомуми мәйданлы, шуның 221,7602 гектары – җаваплылыгы чикләнгән «Управляющая компания «Алабуга-2.Нефтехимия» җәмгыяте милкендә, 0,0004 гектары дәүләт милкендә булган авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен түбәндәге кадастр саннары белән Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләрдә күрсәтелгән чикләрдә җир асты байлыкларыннан файдалану максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:07:320004:1037 | 2,4 |
| 16:07:320004:1039 | 0,0004 |
| 16:07:320004:1084 | 56,4312 |
| 16:07:320004:1087 | 40,1016 |
| 16:07:320004:1088 | 122,8274 |
| Барлыгы | 221,7606. |

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин